**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

05.12.2025 № 1421

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының педагогик хезмәткәрләргә – Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы мәгариф оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән ай саен кызыксындыру өстәмәсе бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 18 гыйнварындагы 21 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 29 декабрендәге 1270 номерлы «Педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен кызыксындыру өстәмәсе билгеләү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 15 ноябрендәге 1214 номерлы карары нигезендә, педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ярдәм итү һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында кадрларны эшкә калдыру максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Педагогик хезмәткәрләргә - Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының мәгариф оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 18 гыйнварындагы 21 номерлы карары белән расланган (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 22 июлендәге 710 номерлы, 2025 елның 14 февралендәге 177 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән ай саен кызыксындыру өстәмәсе бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 14 пунктта:

– дүртенче абзацта «2510 сум» сүзләрен «10000 сум» сүзләренә алмаштырырга;

- бишенче абзацта «2510 сум» сүзләрен «10000 сум» сүзләренә алмаштырырга;

2) 15 пунктта:

- дүртенче абзацта «2510 сум» сүзләрен «10000 сум» сүзләренә алмаштырырга;
- бишенче абзацта «2510 сум» сүзләрен «10000 сум» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 01 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин